ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.06.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1718**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында инвалидларны «Социаль такси» социаль автобус белән йөртүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 18 маендагы 1311 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында инвалидларны «Социаль такси» социаль автобус белән йөртүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 18 маендагы 1311 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Социаль такси» социаль автобусы белән йөртүгә тарифлар» 2 нче кушымтаны, әлеге карар кушымтасында каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштыруны һәм «Зеленодольская правда» һәм «Яшел Үзән» газеталарында бастыруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) Д. А. Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 27 июнендәге
1718 номерлы карарына
кушымта

«Социаль такси» социаль автобусы белән йөртүгә
тарифлар

1. Зеленодольск шәһәре эчендә йөрткәнгә бер кешедән 90 сум
2. Шәһәрдән читтә хәрәкәтләнгәндә 1 км –12 сум

Җиде яшькәчә балаларга (7 яшьне дә кертеп) йөрү бушлай.